**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«КОМСОМОЛЕЦ» АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«5» декабрь 2019 ел № 11/3

**2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар планы чорына**
**Комсомолец авыл җирлеге бюджеты турында**

1 статья

1. 2020 елга Комсомолец авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) Комсомолец авыл җирлеге бюджеты керемнәренең гомуми күләмен 4297,2 мең сум итеп;

2) Комсомолец авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 4297,2 мең сум итеп;

3) Комсомолец авыл җирлеге бюджеты кытлыгын 0 сум итеп.

2. 2021 елга һәм 2022 елга Комсомолец авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) 2021 елга Комсомолец авыл җирлеге бюджет керемнәренең гомуми күләмен 5141,6 мең сум, 2022 елга – 5305,35 мең сум итеп;

2) Комсомолец авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен:

- 2021 елга 5141,6 мең сум, шул исәптән шартлы рәвештә располанган чыгымнарны – 126,37 мең сум;

- 2022 елга 5305,35 мең сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнарны 260,85 мең сум күләмендә;

3) 2021 елга Комсомолец авыл җирлеге бюджеты кытлыгын 0 сум һәм 2020 елга 0 сум итеп.

3. Комсомолец авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын расларга:

- 2020 елга әлеге карарга 1 кушымта нигезендә;

- 2021 һәм 2022 еллар планы чорына әлеге карарга 2 кушымта нигезендә.

2 статья

1. 2021 елның 1 январена Комсомолец авыл җирлеге эчке муниципаль бурычының югары чиген 0 сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча эчке бурычның югары чиген 0 сум күләмендә расларга.

2. 2022 елның 1 январена Комсомолец авыл җирлеге эчке муниципаль бурычының югары чиген 0 сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча эчке бурычның югары чиген 0 сум күләмендә расларга.

3. 2022 елның 1 январена Комсомолец авыл җирлегенең муниципаль эчке бурыч чиген 0 сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча эчке бурычның югары чиген 0 сум күләмендә расларга.

4. 2020 елда бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары хисабына мөмкин булган гарантия очраклары буенча муниципаль гарантияләрне үтәүгә Комсомолецавыл җирлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләре гомуми күләмен 0 сум; 2021 елда – 0 сум, 2022 елда 0 сум күләмендә расларга.

3 статья

1. Комсомолец авыл җирлеге бюджетында 2020 елга фаразланган керемнәр күләмен әлеге карарга 3 кушымта нигезендә исәпкә алырга.

2. Комсомолец авыл җирлеге бюджетында 2021 һәм 2022 еллар планы чорына фаразланган керемнәр күләмен әлеге карарга 4 кушымта нигезендә исәпкә алырга.

4 статья

1. Комсомолец авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген әлеге карарга 5 кушымта нигезендә расларга.

2. Комсомолец авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеген әлеге карарга 6 кушымта нигезендә расларга.

5 статья

1. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44.13 маддәсе нигезендә Комсомолецавыл җирлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле бюджетара субсидияләр күләмен расларга:

- 2020 елда – 387,9 мең сум;
- 2021 елда – 202,5  мең сум;
- 2022 елда 202,5 мең сум күләмендә.

2. 2020 елда һәм 2021, 2022 еллар планы чорында Комсомолецавыл җирлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына әлеге маддәдә каралган бюджетара субсидияләрне күчерү ай саен тигез өлешләр белән башкарыла.

6 статья

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44.13 статьясы нигезендә Комсомолец авыл җирлеге бюджетыннан Тукай муниципаль районы бюджетына тапшырыла торган башка бюджетара трансфертлар күләмен расларга:

- төзекләндерү кысаларында авыл җирлекләре автомобиль юлларын карап тоту (юлларны кышкы чистарту) буенча вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләрне тапшыруга 2020 елга – 816,2 мең сум, 2021 елда – 1856,6 мең сум, 2022 елда 1920,9 мең сум күләмендә;

- территорияне төзекләндерү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләрне тапшыруга 2020 елга 48,1 мең сум күләмендә;

- җирлек халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ялны оештыру өчен шартлар тудыру буенча чараларны тәэмин итүгә төзелгән килешүләр буенча 2020 елга – 816,2 мең сум, 2021 елга – 1856,6 мең сум, 2022 елга 1920,9 мең сум күләмендә.

2020-2022 елда бюджетара трансфертларны күчерү ай саен тигез өлешләр белән

башкарыла дип билгеләргә.

7 статья

1. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44.13 статьясы нигезендә чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен, Комсомолец авыл җирлеге бюджетыннан Тукай муниципаль районы бюджетына күчерелергә тиешле бюджетара трансфертлар күләмен 2020 елга – 86,9 мең сум, 2021 елга – 86,9 мең сум, 2022 елга 88,3 мең сум күләмендә расларга.

2. 2020-2022 елларда Тукай муниципаль районы бюджетына Комсомолец авыл җирлеге бюджетыннан әлеге статьяда каралган бюджетара трансфертларны күчерү ай саен тигез өлешләр белән башкарыла дип билгеләргә.

8 статья

1. Комсомолецавыл җирлеге чыгымнарының ведомство структурасын расларга:

- 2020 елга әлеге карарга 7 кушымта нигезендә;
- 2021, 2022 еллар планы чорына әлеге карарга 8 кушымта нигезендә.

2. Бюджет ассигнованиеләрен бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне расларга:

- 2020 елга әлеге карарга 9 кушымта нигезендә;
- 2021, 2022 еллар планы чорына әлеге карарга 10 кушымта нигезендә.

3. Бюджет ассигнованиеләрен бюджет чыгымнарының максатчан статьялары (муниципаль программалар һәм эшчәнлекнең программасыз юнәлешләре), бюджет чыгымнары классификациясенең чыгымнар төрләре төркемнәре, бүлекләре, бүлекчәләре буенча бүлүне расларга:

- 2020 елга әлеге карарга 11 кушымта нигезендә;
- 2021, 2022 еллар планы чорына әлеге карарга 12 кушымта нигезендә.

4. Тукай муниципаль районы бюджетының гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә юнәлдерелгән бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 2020 елга – 2,9сум, 2021 елга – 3,1 сум, 2022 елда 3,1сум күләмендә расларга.

9 статья

Комсомолец авыл җирлеге бюджетында граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләр күләмен 2020 елга – 1903,37 мең сум; 2021 елга – 2588,71 мең сум; 2022 елга 2591,05 мең сум күләмендә расларга.

10 статья

Комсомолец авыл җирлеге бюджетында хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләрне тормышка ашыру өчен авыл җирлекләре бюджетларына субвенцияләр күләмен 2020 елга – 190,3 мең сум; 2021 елга – 25,89 мең сум, 2022 елга 25,9 мең сум күләмендә расларга.

11 статья

Комсомолец авыл җирлеге бюджетында авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль районнар бюджетларына субвенцияләр исәбеннән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсен

тигезләүгә Тукай муниципаль районы бюджетыннан дотацияләр күләмен 2020 елга– 19,03 мең сум; 2021 елга – 25,89 мең сум; 2022 елга 25,9мең сум күләмендә расларга.

12 статья

2020 елда Комсомолец авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләр, шулай ук авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары һәм муниципаль казна учреждениеләре хезмәткәрләре санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

13 статья

Товарлар белән тәэмин итүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә Комсомолец авыл җирлеге исеменнән төзелгән контрактлар өчен түләүгә (әлеге муниципаль контрактларның шартлары нигезендә 2018 елда түләнергә тиеш) файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләре калдыгы суммасыннан артмаган күләмдәге Комсомолец авыл җирлеге бюджеты калдыклары 2020 елда, Комсомолецавыл җирлеге Башкарма комитеты тиешле карар кабул иткән очракта, әлеге максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә.

14 статья

Әлеге карарны Комсомолец авылы территориясендәге (Яр буе урамы, 15, административ бина) махсус стендларда урнаштырып, халыкка игълан итәргә.

15 статья

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары төзелгән килешүләр нигезендә Комсомолец авыл җирлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыралар.

16 статья

Әлеге карар 2020 елнын 1 январеннан үз көченә керә.

ТР Тукай муниципаль районы
Комсомолецавыл җирлеге Башлыгы О.В. Сурова